| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУСЛЮМОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_03.03.2021__ с. Муслюмово №___104___

**«2021 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 608 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йорттагы гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешле сыйфатта булмаган һәм (яки) билгеләнгән вакыттан узып киткән өзеклекләр белән хезмәт күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 нче августындагы 491 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «2020 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» 2019 елның 14 декабрендәге ПУ-746 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 3 декабрендәге 1097 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «2021 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 608 номерлы карарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән милекчеләр һәм гомуми җыелышта капиталь ремонт өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урын милекчеләре өчен капиталь ремонт өчен түләү күләме» дигән 3 нче кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**